# Тема. Хәсән Туфанның

# «Кайсыгызның кулы җылы?»

# Кайсыгызның кулы җылы?

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Күлмәк җиңен ертасымы?—
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:

Кайт!..— дип хатлар килделәр.
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
— Бусы — алкалары,
Бусы — кабере...— диделәр.

***1 строфада “бәйлисе бар йөрәкне” сүтезмәсе нинди мәгънәне аңлата? Йөрәкне бәйләп булмый бит?***

Җавап. ***Авырткан җирне бәйлиләр, ә бу очракта тынычлык, юану эзләү.***

***2 нче строфада мәгънәсен безгә биографиясе аңларга булышыр. Ул күп елларда кайда булган?***

***«Сугышлардан замана туктап торган арада» – бу тарихыбызда кайсы вакыт икән?***

Җавап. ***Сталин үлгәннән соң.***

***“Яраларны ямаштырып” сүзтезмәсе нинди мәгънәгә ия?***

Җавап. ***Өмет итү, барысы да үзгәрер дип көтү.***

***Алдагы строфадан  без нәрсә турында белдек?***

Җавап. ***Якын кешесе үлгән.***

***“Юллар... Озын иделәр” автор нәрсә әйтергә теләгән?***

Җавап. ***Күп еллар кайта алмаган.***

***Бу кеше аңа никадәр якын булды икән, шигырьдән шул юлларны табыгыз.***

***Әгәр тагын килсәләр,***
***— Сау! — дип хәбәр бирсәләр,***
***Вулканнарга керер идем,***
***Шундадыр ул... дисәләр.***

**«Бирде дөнья кирәкне,**

**Еламаска өйрәтте…»**

***бу юллар артына нинди мәгънә салынган?***

Җавап. *Герой бик күп кайгылар күргән. Бер-бер артлы кайгылар килгәндә кешенең күз яшьләре кибә, ул моны бик авыр булса да зур сабырлык белән кабул итәргә өйрәнә.*